**МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___23.12.2021_____ г.Казань № _372/2-пр________

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында” 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында” 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 2016 елның 29 декабрендәге 249/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 27.12.2021 372/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) каршында киңәшмә орган булып тора, ул Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган башка оешмаларның хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтелүгә хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне, аларның нәтиҗәлелеген һәм иминлеген, халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелекнең дәүләт системасын камилләштерү мәсьәләләрен карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.2. Иҗтимагый совет составы һәм саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафынан раслана торган министрлык, дәүләт комитеты, ведомство каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары күрсәтмә характерда була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда алып бара.

1.6. Иҗтимагый совет эше ихтыярый нигездә, ачык һәм партнерлык принципларында һәм катгый Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә оештырыла.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданнар җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләткә карамаган башка коммерциячел оешмаларның хокукларын яклау;

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итү, Министрлык эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы һәм ачыклыгы принцибын тормышка ашыру;

башкарма орган эшчәнлегенә иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыру.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Министрлык карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирүне арттыру;

җәмгыятьтә коррупциячел күренешләргә каршы чыгуны булдыру.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси вазгыятьне исәпкә алып, үзгәртелергә һәм тулыландырылырга мөмкин.

2.4. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

тиешле өлкәдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы тору эшчәнлегендә катнаша;

Министрлык тарафыннан эшләнә һәм Иҗтимагый совет утырышында алдан каралмыйча кабул ителми торган норматив хокукый актлар проектларына «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингында катнаша;

Министрлыкның дәүләт сатып алулары нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

вакантлы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру буенча конкурс комиссияләре һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә аттестация уздыру буенча аттестация комиссияләре эшендә катнаша.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган министрлык, дәүләт комитеты, ведомство каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә оештырыла.

3.2. Министрлык Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары

сайлана. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә Иҗтимагый совет тарафыннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (алга таба - министр) мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәис урынбасарының шәхси гаризасы буенча яки Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил итүче Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме тәкъдиме буенча карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы секретарен билгеләп куя.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләр срогы Иҗтимагый Советның яңа оешкан составының беренче утырышы уздырылган көннән өч ел тәшкил итә.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән Министрлык боерыгы нигезендә түбәндәге очракларда туктатып торыла:

ул Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләнгәндә;

аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

ул дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле буларак теркәлгәндә, шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта;

Нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләр булганда.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләр срогы тәмамлангач;

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза биргәндә;

сәламәтлеге аркасында Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганда;

судның аңа карата чыгарылган гаепләү карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә ул эшкә яраксыз яисә билгесез югалган дип танылганда;

аның тарафыннан этика нормалары тупас бозылганда – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) катнашмаса;

Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары йөкләмәләрен нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) үтәмәсә;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы

һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда;

ул чит ил гражданлыгын (подданствосын) алганда;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктатканда;

Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгәндә.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы йә Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта, Министрлык боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә әлеге типлаштырылган Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган хәлләр килеп чыгу турында хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Министрлык инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ. б.), дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, шәхси белешмәләр булган мәгълүматны һәм файдалануы чикләнгән мәгълүматны куллануга бәйле катнашу федераль законнар нигезендә чикләнә торган чаралардан тыш, катнашырга;

үз инициативасы белән аналитик язмалар, нотыклар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм Иҗтимагый советка җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларының көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырылучы затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

Иҗтимагый советның әлеге типлаштырылган Нигезләмәдә каралган эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган эксперт төркемнәре, эшче төркемнәр, комиссияләр, башка эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары,

Иҗтимагый совет рәисе һәм башкарма орган тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә итеп рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы белән дә уздырыла, алар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган һәм шул башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан каралмыйча кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә (мондый исемлек Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган һәм шул башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан каралмыйча кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган) каралган һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына һәм башкарма органның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрелә торган норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, алар тулы хокуклы булып санала. Иҗтимагый совет әгъзасының утырышта шәхси катнашу мөмкинлеге булмаганда, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм үз фикерен Иҗтимагый советның башка әгъзасына язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша тапшырырга хокуклы, бу хакта ул Иҗтимагый совет рәисенә, яисә рәис урынбасарына яки Иҗтимагый советның җаваплы секретарена алдан хәбәр итәргә тиеш. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары исәбенә үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган әгъзалары да керә.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актларны) карау алар Министрлык тарафыннан Иҗтимагый советка җибәрелгән көннән соң ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирүне уздыру Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин, сораштыру нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана, ә ул булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон элемтә яки тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең тәңгәллеген һәм аларның документаль раслануын тәэмин итә торган башка элемтә аша документлар белән алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта, рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына, аны үткәрү датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирелергә тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк

булганда, карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча Министрлыктан өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышын Иҗтимагый совет рәисе үткәрә, ә ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләре нигезендә кабул ителә торган карарлары күрсәтмә характерга ия һәм кызыксынучы затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә йә Иҗтимагый совет карары буенча бүтән ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый совет сайтында яисә Министрлык сайты кушымтасында урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эшенең планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет күрсәтмәләрен, Иҗтимагый совет беркетмәләрен һәм башка документларны имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән гарызнамәләрне, күрсәтмәләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларны һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми булмаган вакытта аның функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый Совет рәисенә раслауга тапшыра;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый Советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышының урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый советның һәм Министрлыкның оештыру хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә

ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп тора;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңланырга һәм фикер алышынырга тиешле мәсьәләләрне әзерләү өчен эшче, эксперт төркемнәренә һәм башка эшче органнарга берләшергә, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, материаллар әзерләүгә җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

5.12.1. Иҗтимагый совет аның эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Министрлык башкара.

## 6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр конфликты

6.1. Мәнфәгатьләр конфликты - Иҗтимагый совет әгъзасының үз бурычларын тиешенчә, объектив һәм гадел башкаруга (вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга) йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы аркасында килеп чыккан һәм Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынучанлыгы белән Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары арасында каршылык тудырырга мөмкин булган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру объективлыгына һәм гаделлегенә йогынты ясый яки йә йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы дигәндә, Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар йә үзе яки өченче затлар өчен хезмәтләр күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге, дип аңларга кирәк.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы мәнфәгатьләр конфликты яисә аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, аның үзенә бу хакта мәгълүм булуга, Иҗтимагый совет рәисенә һәм министрга хәбәр итәргә тиеш, ә Иҗтимагый совет рәисе бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе мәнфәгатьләр конфликты яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аның үзенә мәгълүм булуга, министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки

китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш, шул исәптән мәнфәгатьләр конфликты ягы булып торучы Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә туктатып тору яисә туктату турында министрга тәкъдим кертү юлы белән дә.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегендәге коррупциячел хәвеф-хәтәрләрне бәяли һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашуына юл куймау максатларында аларны минимальләштерү буенча чаралар күрә.

Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында үзенә мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне эчендә бу хакта язма рәвештә министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында үзләренә мәгълүм булган Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне эчендә бу хакта язма рәвештә министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына хәбәр итәләр.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алган очракларда, Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында министрга тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору турында министр карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгара торган шартлар бетерелмәгән яисә Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты расланган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турында министрга тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турында министр карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгара торган шартлар бетерелгән (расланмаган) һәм (яисә) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен яңарту турында министрга тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен яңарту турында министр карары Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш.